Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге Карашай-Саклау авылы
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1 15.11.2019

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль
районы Карашай-Саклау авыл җирлеге
Карашай-Саклауавылы халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә :«I группа инвалидлар, көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, 2020 елда 300 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

ӘЙЕ ЮК”

сораву буенча 2019 елның 15 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде,
2019 елның 15 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 226 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 147 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 147 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә булды:

1. Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылында узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.
2. «I группа инвалидлар, көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, 2020 елда 300 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

-Карашай Саклау авылы зиратын коймасын тоту;
- Карашай Саклау авылындагы су башнясына янгын краны сатып алу һәм урнаштыру;
- Карашай Саклау авылында Сабантуй мәйданына эскәмияләр сатып алу;

- Карашай-Саклау авылында массакулэм чараларга бүләкләр алу (Сабантуй, юбилярлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Балаларны яклау көне)
- Карашай Саклау авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм урнаштыру;;
-Карашай Саклау авылы зиратларында янгын куркынычсызлыгы өчен су савытлары сатып алу;;
- Карашай Саклау авылында көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю һәм чистарту.;
- МТЗ-82.1 тракторына ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу;;
-кыш көне Карашай Саклау авылларындагы юлларны кардан чистарту;
- Карашай Саклау авылы территорияләрен куак һәм агачлардан чистарту;
- район газетасында некрологларны бастырып чыгару; мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга («әйе» - 147, «юк»-0).

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Карашай-Саклау авылы, Ленин урамы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева